СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

22 октябрь, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 119 (8131) | Бәясе билгеләнгәнчә

## ЯШӘ, КОЯШ, ЯШӘ, ЧИШМӘ, ЯШӘ, АВЫЛ, ЯШӘСӘГЕЗ БЕЗ ДӘ ЯШӘРБЕЗ

## Октябрь җирендә бәйрәм

**(«Уңыш - 97» бәйрәменнән репортаж).**

Рәсемнәрдә: кунакларны шулай каршыладылар







Бу көнне якташлары белән уңыш бәйрәме шатлыгын уртаклашырга килүчеләрне салкын җил дә, куе болытлар арасыннан менә - менә коелырга торган яңгыр да туктата алмады. Бәйрәм итәргә хакы бар иде шул октябрьлеләрнең: быел моңарчы күрелмәгән мул уңыш алып, дәүләт амбарларына 86 мең тонна ашлык салдылар алар. Шуңа да бәйрәм кәефе һәр җирдә бөркелеп, кунаклар чакырып та торды: җанлы сәүдә рәтләрендә дә, бизәкле мәйданда да, аллы - гөлле сәхнәдә дә.

Ә кунакларның иң тансыгы бу көнне «Татнефть» АҖннән генераль директор Р.Г.Галиев җитәкчелегендәге вәкаләтле делегация булды. Аларны кунакчыл итеп, ипи - тоз һәм күңелле такмаклар белән бизәкле капка янында чая Норлат кызлары зурлап каршы алдылар. Бездә чыгарыла торган нефть күптән һәм нык итеп район халкы мәнфәгатенә хезмәт итә, быел исә нефть чыгаручылар Уңыш бәйрәмендәге күп чараларны уздыруда да матди ярдәм күрсәттеләр.

Бәйрәмне тантаналы ачу сәгать 10да театрлаштырылган композиция белән башланып китте. Менә янып торган гигант тюльпанның таҗы ачыла, аннан башактан такыя кигән кызлар чыгалар. Сәхнә алдындагы мәйданда җиргә җылылык һәм яктылык бирүче символик кояшның якты нурлары пәйда була. Гимн тавышы астында Татарстан Республикасы флагы күтәрелә. Аны күтәрү хокукы быел данлы комбайнчылар Р.К.Насыйбуллин («Алга» КХАсы), В.В.Булатов, В.И.Таймуллин (МТС) һәм И.В.Николаевка (Мичурин исем. КХА) бирелгән иде.

Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин, игенчеләрне бәйрәм белән эчкерсез котлап, агропромышленность комплексы хезмәтчәннәренең үзара берләшеп үз алларына куйган бурычларны намус белән үтәп чыгуларын билгеләде. Октябрьлеләр республикада беренче булып икмәк сату буенча дәүләт заказын уңышлы үтәделәр һәм бөртек тапшыру буенча иң яхшылар рәтенә чыктылар. Терлекчелектә дә сизелерлек уңышлар бар, күп кенә социаль мәсьәләләр уңай хәл ителә. Боларның һәммәсе кешеләрне чын - чынлап куандыра - димәк, район потенциалы әле саекмаган, кешеләр хезмәткә хөрмәтләрен җуймаганнар, яхшыга ышаныч сакланган. Аннан соң чыгыш ясаган Р.Г.Галиев авыл эшчәннәренә басуда яулаган җиңүләре уңаеннан котлау сүзләре җиткерде, нефть чыгаручылар киләчәктә дә районның социаль - икътисадый программасын хәл итүдә үз өлешләрен кертергә тырышачаклар, дип ышандырды.

Бәйрәм дәвам итте. Эстрададан яраткан җырлар яңгырады, спорт ярышлары башланды, Казан аэроклуб парашютчылары, Самара спорт клубы мотоциклчылары үз осталыклары белән шаккаттырдылар.

## Ашыксаң да сак кылан

### «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

**Авылда кыр эшләренең мәшәкате бүген - иртәгә генә бетәр төсле түгел әле. Кичәге көнгә район буенча шикәр чөгендере барлык мәйданның 71 процентыннан казып алынды, шул исәптән соңгы бер көндә 218 гектарда башкарылды. Ул эшне тагын бер хуҗалыкта - «Кондырча»да тәмамладылар. «Тәрнәс», Кузнецов исемендәге, «Киекле», «Якты Күл» «Заветы Ильича, «Родина» хуҗалыкларында бу эш барлык мәйданның 81 - 92 процентында башкарылды. Ә менә «Комбайн», Синдряков исемендәге, «Үрнәк» хуҗалыкларында чөгендер казу планы 50 - 56 процентка гына үтәлгән, нефтебаза ярдәмче хуҗалыгында бу эшнең яртысы да башкарылмаган әле, ә МСО ярдәмче хуҗалыгында татлы тамыр җыюның кайчан тәгәлләнәсе бөтенләй билгеле түгел.**

**Дәүләтка шикәр чималы сату буенча килешү йөкләмәсе 40 процентка диярлек үтәлде. 19 октябрьдә заводның кагат кырына 1600 тоннадан артыграк чөгендер кабул ителде. Заводның ярдәмче хуҗалыгы йөкләмәдән тыш та 375 тонна чөгендер тапшырды инде. «Кондырча» килешү йөкләмәсен 67, Хафизов исемендәге хуҗалык 58, Кузнецов исемендәге хуҗалык 52 процентка үтәделәр. Шул ук вакытта «Алга», «Татарстан», «40 лет Победы» хуҗалыкларыннан, «Агрохимсервис», нефтебаза һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларыннан китерелгән чөгендер һаман да бик аз, бу мәсьәләдә «Дуслык»ның позициясе дә аңлашылмый.**

**Икенче бер кыйммәтле культура - бөртеккә калдырылган кукурузны суктырып алу эше дә көн кадагындагы бурыч булып тора. Кичәге көнгә 650 гектар чамасы мәйданнан бөртек җыеп алынса да, күп кенә хуҗалыкларда ул эш канәгатьләнерлек түгел әле. Хәзер МТСның шушы эшкә махсус көйләнгән «Кейс»лары хуҗалыкларга чираттан булышалар. Әмма, аларның киеренке эш режимына яраклашырга тырышудан ашыгу галәмәтеме, орлыкны элеваторга ташучы машиналарның кайберләренең әрҗәләре тиешенчә җиһазланмаган булу, япмалары булмау аркасында шактый кукуруз юлга чәчелеп - сибелеп бара. Ашыгабыз дип ашлыкка шулкадәр дә битараф карарга һич тә ярамый бит инде.**

## Безгә «Мунча ташы» килә!

*Сәнгать сөючеләр, сөенегез! Октябрьнең 27сендә район мәдәният йорты сәхнәсендә Түбән Кама шәһәренең «Мунча ташы» музыкаль - тамаша театры чыгыш ясаячак. Бу коллектив белән азмы - күпме таныш булган кешеләр белә: тамашалары искиткеч кызык була түбән камалыларның. Бу юлы исә алар Норлат халкы хөкеменә «Забастовка» дип аталган көлкеле музыкаль тамаша тәкъдим итәчәкләр.*



## Хөрмәтле дуслар!

**1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу бара. Язылу бәясе ярты елга 26.400, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.**

**Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.**



## Рәсәй безнең ашлыкны алкышлый

Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев һәм Премьер - министр Ф.Х.Мөхәммәтшин исеменә Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе В.Черномырдиннан котлау телеграммасы килде. Анда мондый сүзләр бар:

«Россия Федерациясе хөкүмәте исеменнән һәм шәхсән үзем сезне югары нәтиҗәләргә ирешүегез белән ихлас тәбрик итәм. Татарстан Республикасы Россия Федерациясендә югары сыйфатлы ашлык җитештерүдә төп җитештерүчеләрнең берсе булып тора һәм үзендәге авыл хуҗалыгы эшчәннәре белән хаклы рәвештә горурлана ала, алар исә ил өчен гадәти булмаган чорда мул уңыш үстерделәр һәм җыеп алдылар».

## Ипи белән аракыга бәя үзгәрмәячәк

Премьер - министр Ф.Х.Мөхәммәтшин үткәргән киңәшмәдә яңа елга кадәр Татарстанда ипигә һәм икмәк ризыкларына бәяләр үзгәрмәячәген белдерде. Быел уңышның зур булуы бәяләрне элекке дәрәҗәдә саклап калырга мөмкинлек бирә, диде ул. Шул ук көнне үткәргән икенче киңәшмәдә Премьер республикадагы аракы заводларында чыгарыла торган продукциягә дә, аерым алганда аракыга бәяләр күтәрелмәскә тиеш диде. Шул ук вакытта әле безгә читтән хәмер керүнең тәртипкә салынмаган булуы да күрсәтелде.

## Түләүдә аерымлык

1 октябрьдән торак бүлмәләрен җылылык белән тәэмин итү хезмәтенә дифференцияле түләү кертелде. 1996 - 97 еллардагы җылыту сезонының климатик шартларын исәпкә алып, гомумторак мәйданының 1 квадрат метрын җылыткан өчен түләүгә быелның 1 февраленнән гамәлдә булган тарифка карата исәп - хисап аермасы 1 сентябрьдән ясала. Татарстан Министрлар Кабинеты шундый карар кабул итте. Аннан тыш кайнар су белән үзәкләштерелгән тәртиптә тәэмин итү хезмәтенә дә дифференцияле, ягъни аерымлыклы түләү тарифы расланды. Ул торак шартларына бәйле.

## Яшьлегеңдә күп эзләнсәң

10 - 11 октябрь көннәрендә Казанда яшь галим һәм белгечләрнең III республика фәнни конференциясе уздырылды. Монда Татарстан калаларыннан, Уфа, Түбән Новгород, Ульяновск, Йошкар - Ола һәм башка төбәкләрдән 400ләп яшь галим һәм аспирант, башкалабызга килеп, үзләренең гыйльми хезмәтләре турында фикер алышты. Конференцияне Татарстан Республикасының Яшь галим һәм белгечләр иҗтимагый хәрәкәте, җөмһүриятнең Балалар һәм яшьләр эше дәүләт комитеты оештырган иде.

(«Шәһри Казан»нан).

# ЯШӘ, КОЯШ, ЯШӘ, ЧИШМӘ, ЯШӘ, АВЫЛ, ЯШӘСӘГЕЗ БЕЗ ДӘ ЯШӘРБЕЗ

## *Атлар чаба, атлар...*



Бу сабантуйда ат чабышларының төп спонсоры «Татнефть» АҖ булганга күрә, анда җәмгыятьнең барлык подразделениеләреннән республикада гына түгел, илкүләм ярышларда да узышкан чабышкыларның катнашуы табигый иде. Чабышларның гаять дәрәҗәдә киеренке баруы да иң беренче чиратта шуннан булды дип карарга кирәк. Һәм ат чабышларына битараф булмаган кеше бу юлы нәкъ менә безнең район данын яклаучы атлар өчен генә җан атып тормыйча, ә сокланып туймаслык башка атлар өчен дә дулкынланып, күңеленә яткан, өметле күренгән чабышкыларның һәркайсы өчен ихластан борчылып күзәткәндер бу ярышларны. Ә ярышта игътибарга лаек мизгелләр шактый булды. Дөрес, безнең район атлары бу юлы хуҗаларына төп призларны яулап алып бирә алмадылар: «Ока»лар кунакларга насыйп булды. Аерым алганда, яшь юртаклар һәм чиста токым яшь чаптарлар арасында беренчелек Чаллы ат спорты мәктәбеннән Хот - Шоу Маклайн кушаматлы һәм Знаток кушаматлы туры айгырларга, дүрт яшьтән олырак юртаклардан Әлмәт районының Токарликов исемендәге хуҗалыгының Фристайл туры айгырына, чиста токым карт чаптарлардан Зәй районы хакимияте башлыгының Оберт кушаматлы кара туры айгырына бирелде.

Шулай да безнең район данын яклаган атлар өчен җан атучылар да аз дулкынланмагандыр. Чөнки район хакимиятенең Фест - Американ кара туры юртагы үзара узышта баш килгән Фристайлдан секундның уннан беренә генә калышып, финал узышында да өченче нәтиҗә күрсәтте. «Дуслык» хуҗалыгыннан Гигант кушаматлы туры айгыр яшь юртакларның икенче төркемендә иң алдан килеп финалга үтте һәм анда да призлы, өченче нәтиҗә күрсәтте. Шул ук хуҗалыкның Эльбрус кушаматлы туры айгыры җирле токым чаптарлар узышында беренче, Мичурин исемендәге хуҗалыкның Артуры икенче булды. Карт юртаклар арасында безнең ике данлыклы ат - 1600 метрны 2 минут 8,7 секундта үткән Резонанс ( район хакимияте) белән Заманчивыйның («Кондырча») күрсәткечләрен бу көнне кабатлаучы булмады. Башта юртакларны артык иркенләп, икешәрләп кенә чаптырып та, соңыннан яшь һәм карт чаптарларны стартка гомер булмаганча күпләп, көтүләре белән чыгару да үзен сиздерми калмагандыр дип уйларга кирәк.

Дөрес, боларны һич тә безнең атларның бу юлы арткарак калуларын аклау өчен әйтүебез түгел - ярышта кем көчле, шул җиңә. Әмма бу юлы чабышларны оештыруның күзгә ташланып торырдай уйланып бетерелмәгән яклары барыбер бар иде һәм алары киләчәктә искә алыныр дип уйларга кирәк. Өстәвенә, мондый ярышлар традицион булачак, ягъни нефтьчеләр ат чабышлары сезонын ябуны моннан ары һәр елны Норлатта оештырачаклар ди бит әле.

## *Көрәш - бәйрәм бизәге*

Милли көрәш буенча ярышларның башлангыч этабы бер атна элек үткәнлектән, бу көнне көрәш келәмендә финалга чыгучылар гына көч сынашты. МПП егетләре исә аеруча актив булды: өч үлчәү категорияләре буенча призлы урынны яулаган 9 егетнең бишесе әлеге предприятие данын яклады. Зөлфәт Лотфуллин, Мансур Минһаҗев, Фәнил Гайнуллин үз үлчәү категорияләрендә беренче булсалар, Зөлфәт Сөнгатуллин 70 килограммга, Рәмис Гатауллин 80 килограммга кадәрле үлчәүдә көрәшүчеләр арасында өченче урыннарны яуладылар. «40 лет Победы» КХАсыннан Ильяс Садыйков белән Рияз Галиҗанов та җиңүчеләр исемлегенә керделәр. Ильяс җиңел үлчәүдә икенче, Рияз авыр үлчәүдә өченче булды. 80 килограммга кадәрле авырлыкта көрәшүчеләр арасында төрле бәйгеләрдә бил бирмәүче Раил Рәхмәтуллин («Кондырча» КХАсы) да бар иде: икенче урынга чыкты ул. НУРБдан өметле көрәшче Ислам Гайсин да киләчәктә районыбызның оста көрәшчеләре исемлегендә ныклы урын алыр дигән нәтиҗәгә килдек без: Ислам авыр үлчәүдә икенче нәтиҗә күрсәтте.

Бәйрәмнең абсолют батыры исемен яулау өчен көрәш тә киеренке барды. Жирәбә буенча беренче булып келәмгә Зөлфәт Лотфуллин белән Мансур Минһаҗев чыктылар. Бил алышу икенчесенең җиңүе белән тәмамланды.

Көрәшнең хәлиткеч минутлары җитте. Районда үткәрелә торган төрле бәйгеләрдә, бәйрәмнәрдә һичкемгә бил бирмәгән Фәнил Гайнуллин бу юлы да көндәше Мансур Минһаҗевны аркасына салды. Шулай итеп, районның танылган көрәш остасының абсолют батыр исемен сигезенче тапкыр яулавы иде.



## *Милли урамнарда миллилек*

Сабан туе кунакларын Октябрь районында иң күп яшәүче милләт халыклары - татар, рус, чуваш урамнары, аларның гореф - гадәтләрен, йолаларын чагылдырган күренешләр каршы алды. Район җирендә дустанә мөнәсәбәтләрдә яшәгән бу өч милләт халкы өчен әлеге композицияләр уңыш бәйрәменә җыелган халык тарафыннан да табигый кабул ителде.

Татарлар мишәрләрнең туй күренешен күрсәттеләр. Элек - электән матур һәм бай эчтәлекле килен төшерү йоласын Норлат татар халык театры режиссеры Камил Зәбиров сәхнәләштергән. Өстәл тулы сый - нигъмәтләр, татар авылы өен хәтерләткән стеналар, «килен» чиккән, бәйләгән, теккән тастымалларга күмелгән. «Кодалар», «кодачалар»ның телләре телгә йокмый: кара - каршы җырлашып, такмакларын әйтешеп, бал да май һәм җылы сүзләре белән киленне кабул итәләр. Артистлар - Норлат мәдәният йорты хезмәткәрләре, Бикүле, Зирекле клублары, Киекле авылы үзешчәннәре рольләрен оста башкардылар.

Татар туеннан кунакларны рус хатын - кызларының «кич утыру» күренеше каршы алды. Л.Н.Дилмөхәммәтова җитәкчелегендә район социаль - тәэминат бүлеге кызлары һәм Ә.Якупова җитәкчелегендә район мәдәният йорты кызлары тырышлыгы белән бирегә туку станогы, май язгыч, башында кәрҗин үреп утыручы бабае белән мичкә кадәр китерелгән иде. Ә мич авызыннан



кайнар пар бәрелеп торган коймаклар чыга һәм пироглар, тозлы гөмбәләр белән тулы өстәлгә урнаша. Тагын шунысын әйтми мөмкин түгел: дистә еллар татар белән иңгә - иң яшәгән рус халкы урамында чын татар ризыгы чәк - чәк уртак ризыктай лаеклы урында булды.

Район ветераннары Т.Е.Иванова, А.Ефимова, З.Щербакова, Р.Астрова һәм Сәләнгеш авылы үзешчәннәре тырышканнар да соң бу көнне!

Чуваш урамында Урта Камышлы авылыннан «Росинка» халык фольклор ансамбле хакимлек итте. Ансамбль үз репертуарында иң яратып башкара торган күмәк җырларын, биюләрен кунакларга тәкъдим итте. Ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Николай Бочкарев әйтүенчә, Урта Камышлы артистлары халыкны үз иҗатлары белән чирек гасыр куандыралар икән. Яңа елга кадәр юбилейларын үткәрергә исәпләре. Чуваш урамы иң күп халыкны тамаша кылырга җыюы белән үзенчәлекле булды.

## *Казаннарга тиң район үзешчәннәре*

Районның җырчы үзешчәннәре тавышы сабантуй сәхнәсендә дә тынмады. Норлатлылардан Рәсимә Туктарова, Индира Гайсина, Сергей Николаев, Светлана Захарова, Наталья Митрофанова, Сания Котдусова, Норлат балалар музыка мәктәбенең хатын - кызлар ансамбле, Чистайда республика зональ конкурсында җиңүче Ләйсән Җамалиева һәм башкалар чыгышы яңгырады. Концертны Казан артистлары чыгышы дәвам итте. Аннан ике бригада килгән иде. Берсе - сүз остасы, шаян җырлар авторы һәм башкаручысы Алмаз Хәмзин җитәкчелегендә Зөлфия һәм Мөхтәр Минһаҗевлар, икенчесе - үзләре әйтүенчә республикада иң яшь группа, композитор Марат Хөснуллин җитәкчелегендә «Татар җыры - 97» конкурсының I премия лауреаты Рәсим Низамов, яшь җырчы Алсу Хәбибуллина һәм башкаларны берләштергән иде.

## *Көчең булса җиңәсең*

Көзге Сабан туе спорт уеннарыннан башка да үтмәде. Хәер, аларда даими катнашучылар иң беренче эшләре итеп теркәлделәр һәм шуның белән оттылар да, чөнки аркан тарту, гер күтәрү, йөгерү, кул көрәштерүең бер дә юкка булмады: оештыручылар әйтүенчә, приз фонды җәйге сабан туеннан да күбрәк бүленгән иде. Аркан тарту буен-



ча Вячеслав Сафонов (МПП) I урынны яулады һәм иң зур призның берсенә лаек булды. Икенче, өченче урыннарны Ирек Камалов (Зүзәй нефть промыселы), Владимир Шугаев (НГДУ) алдылар. Беренче тапкыр биеклеккә сикерү ярышы үткәрелде һәм ир - атлар арасында Рамил Сәлахов (НГДУ),хатын - кызлардан Татьяна Климова (1 нче мәктәп) җиңүчегә чыктылар. 100 метр арага йөгерүдә Юрий Никитин, хатын - кызлардан Анастасия Баранова («Норлатнефтеразведка») беренчелекне алдылар. Кул көрәше - армрестлингта шулай ук «Норлатнефтеразведка»дан Владимир Еромасов, хатын - кызлардан Хөсәенова (НГДУ) җиңделәр. Шахмат уйнап «җылынучылар» да булды. Алда әйтелгән предприятие хезмәткәре Атлас Гыйльманов иң оста шахматчыга чыкты. Гер күтәрүчеләр арасында ике категория буенча беренчелекне алдагы ярышлардан таныш җиңүче Фәрит Сәләхетдинов (НГДУ), Илшат Гыйззәтуллин (МПП) алдылар. Игътибар иткәнсездер, «Уңыш» бәйрәмендә иң зур призлы урыннар нефтьчеләр кулында булды, ә икенче, өченче урыннарны (аларда да призлар әйбәт иде) җылылык челтәре, сөт - май заводы, шулай ук нефтьчеләр ычкындырмады. Хәер, берән - сәрән генә шәһәргә якын урнашкан Хафизов исемендәге, «Кондырча» КХАлары кешеләренең дә исемнәре бар. Шулай да үз хезмәтләренә багышланган хезмәт ияләрен дә бәйрәмдә, бигрәк тә ярышларда күбрәк күрәсе килгән иде.

**Бәйрәмнән репортажны махсус хәбәрчеләребез Т.Назарова, Р.Гыйльметдинов, Р.Гиняева, Ф.Зиятдинова, Н.Азизов (фото) әзерләделәр.**

# Эшендә дә, гаиләсендә дә...

Сезгә колхозыбызның иң уңган тәҗрибәле, өлкән механизаторларның берсе Нургаяз Нурхәммәт улы Нурхәммәтов турында сөйлисем килә. Нургаяз ага үз гомерен җиргә багышлаган кеше. Аның хезмәте бик күп Мактау грамоталары, кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнеп килде. Авыл халкы аны тыйнаклыгы, тырышлыгы өчен хөрмәт итә. Алдынгылар белән очрашуларда, төрле бәйрәм кичәләрендә аның урыны һәрчак сәхнә түрендә була. Ә инде яңа ел кичәләрендә халык соравы буенча «Гөлҗамал» көен сузып җырлавын әле дә хәтерлиләрдер... Яшьләр остазы булган Нургаяз аганы хезмәттәшләре дә ихтирам итәләр. Яшьләргә ул үзенең төрле киңәшләрен бирә, техниканы яратырга, сак тотарга өйрәтә. «Техниканы вакытында карап, майлап - көйләп торсаң гына яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин һәм эшең дә уңышлы булыр»,- ди ул. Үзе турында күп сөйләргә яратмый, ә инде иптәшләре турында горурланып сөйли белә. Янәшәсендә эшкә өйрәнгән яшь егетләр хәзер инде үзләре ышанычлы механизаторлар булып җитештеләр. Бүгенге көндә уңган механизатор машина - трактор паркында склад мөдире вазифасын башкара.

Нургаяз аганың шәхси тормышын да әйтеп үтмичә булмый.

Нурхәммәтовлар гаиләсе авылда үрнәк гаиләләрдән санала. Гаиләдә ата - ана шатлыгы булып 4 бала тәрбияләнеп үсте. Нургаяз аганың тормыш иптәше Хәлимә апа уңган хуҗабикә була белде. Гомере буе колхозда армый - талмый хезмәтен куйды: чөгендерен дә үстерде, сыерлар да сауды, бозаулар да карады. Хәзер ул лаеклы ялда. Өйдә гаилә җылысын саклап ирен эшкә озатып, эштән кайтканын көтеп ала. Йорт хуҗасының тәртипле ата, менә дигән йорт башлыгы, эшендә алтын куллы механизатор, ил - көн алдында абруйлы кеше булуында, әлбәттә инде, аның да йогынтысы булгандыр. Авырлыклар килсә бергә уртаклашып, кыенлыкларны бергә җиңеп, шатлык - кайгыларны бергә кичереп, бер - береңне хөрмәт итеп яшәгәндә генә шундый матур тормыш юлы узарга мөмкин, минемчә. Аларның балалары да үзләре кебек яшьли хезмәткә өйрәнеп үстеләр. Мәктәптә укыганда уку алдынгылары булдылар. Зур уллары Җәүдәт класстаһы Гөлсинә белән тормыш корып Чаллы шәһәрендә яшиләр. Бер кыз үстерәләр. Кызлары Рәфисә күрше Әмзә егетенә кияүгә чыгып, бүгенге көндә Чаллы шәһәрендә яшиләр. 2 малай үстерәләр. Төпчек кызлары Әминә авылыбызның уңган егете Рәфис Әхмәтвәлиев белән тормыш корды. Мәктәптә 4 нче сыйныфларны укыта, аларның кызлары Әлинә балалар бакчасында тәрбияләнә. Кече уллары Нияз 1992 нче елда Совет Армиясе сафларында хезмәт срогын тутырып кайткач та туган авылында төпләнеп калды. Аңа әтисе кебек техника ярату хас. Һәм менә 5 ел инде «корыч айгыр» иярли. «Тырыш, уңган егет»,- диләр аның турында. Уңган гаилә киләсе елга яңа өй туе уздырырга җыена. Ходай насыйп итсен, киләчәктә яңа өйдә дә шулай матур итеп балаларыгызның игелеген күреп исән - сау яшәргә язсын.

**Зәкия ИСМӘГЫЙЛОВА.**
**Кычытканлы авылы.**



Әлегә Рәфис тулы хокуклы авыл эшчәне түгел. Әмма авылда эшләргә әзерләнә инде. Шулай булмаса, мәктәпне тәмамлауга ук Казан ветеринария институтына укырга кермәс тә, студент елларының иң мөһим этабы - институтны тәмамлау алдыннан туган ягы - Киеклегә диплом алды практикасына кайтмас та иде. Хуҗалыкта Рәфисне, кем әйтмешли, колач җәеп каршы алдылар. Егетне хезмәттә сынау өчен эшнең дә җаваплысын тапшырдылар: хәзер «Киекле» КХАсында зоотехник ул. Иртәгеге көн белгече беренче көннән үк эшкә бөтен күңелен бирде, иртән - иртүк фермага ашыга ул. Бер үк вакытта диплом эше өчен мәгълүмат та туплый.

**Рәсемдә: Р.Ганиев.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# Яңа тормыш бирәләр




## Фоторепортаж

Скважиналар ремонтлаучылар - нефть чыгаруга турыдан - туры бәйле булмасалар да, бу эштә мөһим урын тоталар. Сафтан чыккан яисә эксплуатация срогы бетеп килә торган скважиналарга яңа «тормыш» бирәләр алар.

Әйтергә кирәк, скважиналарга капиталь һәм җир асты ремонты үткәрү цехы тулаем «Норлатнефть» идарәсендә яхшы исәптә. Коллективны җитәкләүче Назыйм Габделханович Шәфыйков исә цехны һәрчак югары җитештерүчән, нәтиҗәле, сыйфатлы эшкә туплый. Штаттан тыш фотохәбәрчебез Н.Квашнинаның әлеге рәсемендә сез аны цех мастерлары белән киңәшмә үткәргәндә күрәсез.

Цехның матди базасы елдан - ел байый. База шул бинада урнашкан (астагы рәсем).



### Редакциягә зар белән

# Җаваплылык төшми

Хуҗалыкларда йөклелек буенча һәм бала табу уңаеннан пособиеләрнең үзвакытында бирелмәве турында редакциягә әледән - әле хатлар килеп тора, телефоннар шалтырый. Шуңа да бу хакта газета битләрендә берничә тапкыр сүз кузгатылды («Без халык мәнфәгате яклы» - 5 март 1997 ел, «Пособие күләме үзгәрмәде» - 2 июль 1997 ел...). Шуңа карамастан, кайбер ассоциацияләрдә бу проблема хәл ителмәгән килеш кала бирә.

Шушы көннәрдә Муса Җәлил исемендәге КХАдан килгән өч хатын - кызның зары да шул хакта иде.

Шәйдуллина Лилия хуҗалыкта төрле эшне башкарган, баласына 6 ай булган. Аның әйтүенчә, хуҗалыкның бухгалтериясендә аңа бала туу уңаеннан пособие 500 мең сум гына исәпләнгән (әле бирелмәгән).

Әхмәтова Румия бала тапканчы фермада эшләгән, баласына 6 ай, пособие урынына бәясе 250 мең сум белән ике капчык шикәр комы биргәннәр. Калганын да шулай ук санашырга тәкъдим иткәннәр, ул баш тарткан, ә терлекләтә түләргә хуҗалык риза түгел.

Заһирова Миләүшә 11 ай элек бала тапкан һәм озакламый аны җирләгән дә. КХАдан йөклелек буенча акчасы һәм мәетне күмү өчен бирелергә тиешле пособиесен дә ала алмаган.

Хаклык эзләп алар берничә инстанциягә мөрәҗәгать итәләр, әмма «һаман да очына чыга алмадык» диләр. Без кабат социаль иминият фондының Татарстан региональ бүлегенең райондагы уполномоченные В.П.Алексеева белән бәйләнешкә кердек һәм аларны борчыган сорауларны бирдек. Аның тарафыннан элек газетада язганнарга бернинди яңалык өстәлмәсә дә укучыларыбыз үтенече буенча ул аңлатмаларны тагын бер тапкыр кабатлыйбыз.

Йөклелек буенча исәпкә баскан хатыннарга йөклелек һәм бала табуга бәйле пособиеләр, шулай ук бала туу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган пособие акчасы тиешле документлары тапшырылганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча түләнә. Аның күләме балаларның санына бәйсез рәвештә 1997 нче елның 1 нче гыйнварыннан 1252350 сумны тәшкил итә (РФдә кабул ителгән 15 минималь хезмәт хакы 83490 x 15). Балага яшь ярым тулганчы өйдә утыручылар пособиене айныкын - айга алып барырга тиешләр. Аның күләме 200 мең сум. Бу таләпләр РФның социаль иминият фонды турында положениедә беркетелгән. Социаль иминият средстволарын дөрес итеп бүлү һәм тоту, пособиеләрнең үзвакытында түләнүе өчен хезмәткәр эшли торган предприятиенең җитәкчесе һәм баш бухгалтер җаваплы.

Тик социаль иминият средстволары җыю мәсьәләсе гаять четрекле, авыл хуҗалыгындагы акчага кытлык аларның фондка бурычларын көннән - көн арттыра. Мисал өчен Муса Җәлил исемендәге КХАның гына аңа 44 млн сум бурычы җыелган, димәк, фондтан аларга бер тиен дә акча күчерелми дигән сүз. Хәер, башкаларда да бу хәл мактанырлык түгел. Шуңа карамастан, положениедә әйтелгәнчә, җаваплылык заман ничек кенә авыр булмасын ассоциация хуҗаларыннан төшми: пособиеләр хәлдән килгәнчә азык - төлек продуктлары, яки башка әйберләр белән түләнергә тиеш. Әмма шикәр комының капчыгы базарда 200 мең сум булганда 250 мең сумга алудан пособие алучыга әлләни шатлык юк, әлбәттә.

Вафат булучыны күмәргә пособие үтенеч белән мөрәҗәгать иткән көнне бирелергә тиеш, диелә положениедә. Бу очракта инде шикәр комы биреп котылуны гуманлы хәл дип атап булмый, ә бер елга сузуны ничек дип атарга?

Айлар буе эш хакы алмаска күнде халык, редакция, башка учреждениеләр бусагасын таптаса да, чарасызлыктан шул яшь балалы аналар таптар. Матбугаттан, радио, телевидениедән күргәнебезчә, ишеткәнебезчә цивилизацияле илләрдә эш хакын, законда каралган пособиеләрне түләмәгән очракта, кыскасы, кешенең гражданлык хокуклары бозылганда дәгъвачы хөкем итүче дәүләт органнарына мөрәҗәгать итә һәм шунда кешелек хокукларын яклый. Бәлки бездә дә цивилизацияле фикерли башларга кирәктер. Россия хокукый дәүләт булырга тиеш, ди бит РФ президенты.


**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

## Учың кычытса - девиденд керер

Акча турында сүз чыккач, «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең тагын 300 миллион долларлык еврооблигацияләр урнаштыруын әйтмичә мөмкин түгел. Соңгы вакытта кыйммәтле кәгазьләр базарында абруе шактый күтәрелеп киткән «Татнефть» бу юлы да шул рәвешле зур инвестицияләр алырга өметләнә. Ә инде кулларында әлеге җәмгыятьнең акцияләре булган кешеләр түземсезлек белән девиденд көтәргә хаклы.

# Кычытканлы авылы тарихыннан

**Җәүдәт Камалов**



Русча Кичкальня дип аталган чын татар авылы Кычытканлы Октябрь районына кереп «Татарстан» исемле күмәк хуҗалыкны тәшкил итә.

Авыл Кече Чирмешәннең сул кушылдыгы булган Мораса елгасы башыннан сигез чакрым түбәндә өч яктан урман чолгап алган бик матур җирне били. Ул район үзәге Норлат тимер юл станциясеннән 47, Чистай пристаненнән 87, Кама аркылы Мурзиха - Саескан Тавы кичүеннән 105 чакрымда урнашкан.

1917 елга кадәр авыл Казан губернасы Чистай өязе Иске Әлмәт волостена кергән.

1924 - 1927 елларда ТАССРда дүртбаскычлы административ бүленү системасы яши: республика - кантон - волость - авыл Советы. 1927 елда анда 12 кантон һәм 125 волость була. 1910 - 17 елларда Иске Әлмәт волость старшинасы булып Кычытканлы бае Сабитов Шакир эшли. Агалы - энеле Шәһит һәм Шакир Сабитовлар инкыйлабка кадәр кибет тоталар. Икесенең дә өйләре таштан, бер яртысында торак, икенчесендә кибетләре була.

1927 елда кантон - волость звеносы районнар белән алмашына башлый.

БУБК (ВЦИК) карары нигезендә ТАССР 1930 елда 45 районга бүленә. 1928 елда 12 кантонның берсе булган Чистай кантонына кергән Кычытканлы авылы 1930 елның 30 августында төзелгән Биләр районында була. Җитәкчелекне колхозларга тагын да якынайту максаты белән 1934 елны партия ҮКның ноябрь пленумы районнарны кечерәйтү турында күрсәтмә бирә. Шуның нигезендә, 1935 елның 10 февралендә Кычытканлы күрше авыллар белән бергә яңа төзелгән Тельман (үзәге Мамык) районына күчә.

1958 елның 12 июнендә районнарны яңадан эреләндерү башлангач, Тельман районы бетерелә һәм Кычытканлы яңадан Биләр районына, ул да бетерелгәч, 1962 елның декабреннән Октябрь районына кереп кала.

Картлар сөйләвенә караганда, авылның барлыкка килүе XVI гасыр азагына - XVII гасыр башына карый. Аның беренче кешеләре Болгар, Казан ягыннан килеп урнашканнар. Кычытканлыларның сөйләмнәре, күрше авыллар - Иске - Яңа Әлмәт, бигрәк тә Иске - Яңа Әмзә, Көрнәле Әмзәсе, Колбай Морасалылардан аермалы буларак әдәби татар теленә бик якын. Бу факт аларның Болгар, Казан ягыннан килеп урнашуларын раслаучы дәлил булса кирәк.

Казан ханлыгын 1552 елда Явыз Иван яулап алгач, алар көчләп чукындырудан биредәге куе урманлыкка качып килгәннәр дигән риваять бар.

Беренче булып күчеп килгән кешеләр Мораса елгасына Дарник елгасы кушылгач ике аралыктагы, соңыннан Кәҗә Тавы дип аталган калкулыкта урнашканнар. Ул җир куе кычыткан һәм әрекмән үсеп утырган аланчык булган. Яр буенда җир казып, үзләренә торак итеп землянкалар ясаганнар. Игенчелек, терлекчелек, сунарчылык, умартачылык белән шөгыльләнгәннәр. Сарык, кәҗә күп асраганнар. Кәҗә Тавы исеме шуннан калган.

Мораса елгасы үзенең исемен тирә - яктагы авыллардан алда шул елга буенда урнашкан Колбай Мораса исеменнән алган. Кычытканлы да элегрәк күпмедер вакыт Мораса башы дип аталган.

Дарник инеше элек Анатолий ерымы дип йөртелгән. Иске Әлмәт урыслары инешнең югары агымында урман буенда чишмә ачып, аны изге урын итмәкче булганнар. Соңрак аның итәгендә көпчәк тугымы, чана табаны, дуга парлап бөккәннәр. Шуннан Дарник инеше исеме калган. 20 - 30 еллар Кәҗә Тавында яшәгәннән соң куе кычыткан үскән зуррак аланга күчеп утырып «Яңа авыл»га нигез салганнар. Кәҗә Тавы Иске авыл булып калган, яңасы Кычытканлы дип атала башлаган. Анда инде өйләрне бүрәнәдән салганнар. Өйләре кечкенә, үзе бер «тукмак» тәрәзәле булган. Төтен чыгар өчен түшәмдә тишек калдырганнар. Тора - бара утын ягып җылытыла торган мичле ак өйләр сала башлаганнар.

Халык саны арткан саен, корытып урман яндырганнар, ышна ачып чәчүлек җирләрен киңәйткәннәр.

Умартачылык киң таралган кәсеп булган. Умарталыкларга барып йөри торган «Хабетдин сукмагы», «Хәммәтша канавы», «Бәшир юлы», «Хәлил юлы», «Зилә умарталыгы» атамалары шуннан калган. Алар әле дә булса халык телендә кулланыла.

Ике елга арасындагы авыл инде шактый зурайган чорда, авылга каршы якта, Мораса елгасының уңъяк яр буенда берничә чуваш гаиләсе килеп урнаша һәм ул җир «чебил» дип атала башлый. Ләкин чувашлар анда урнашып кала алмаганнар, татарлар аларны кысрыклап чыгарганнар күрәмсең, әмма елганың аръягы «чебил» дип аталып калган.

Бу якларда крепостнойлык булмаган. Крестианнар дәүләтнеке исәпләнгәннәр. Алар дәүләт йөкләмәләрен үтәгәннәр, налог түләгәннәр.

Кычытканлыда Мораса бояры М.С.Золинның 40 дисәтинә җире, урман биләмәләре булган. Ул күбесенчә киндераш, җитен чәчтергән. Атлар, сыерлар асраган, дүрт - биш йөз баш умарта тоткан. Җирен көнлекче крестианнар эшкәрткәннәр. Терлеген, умарталарын караганнар. Үзе бик саран һәм каты куллы хуҗа булган. Урманыннан җиләк тә җыйдырмаган, утын өчен бер чыбык та алдырмаган.

( Дәвамы бар).

## КОТЛЫЙБЫЗ

*Норлат шәһәрендә яшәүче безнең кадерле әниебез **Венера Миншакир кызы Нигъмәтуллинага** 23 октябрьдә 50 яшь тула. Туган көнең белән чын күңелдән котлыйбыз, сиңа исәнлек, озын гомер телибез.*

*Сәламәт бул, әни, рәхәт яшә,*
*озын булсын гомер юлларың.*

***Зөлфия, Эдуард, оныкларың.***



Киекле авылында яшәүче кадерле әниебез **Чәчәк Вәли кызы Гыйләҗеваны** 50 яше тулу белән чын күңелдән котлыйбыз.

Син булганда без бәхетле, әни,
Синең белән якты көнебез.
Безнең белән син дә бәхетле бул
Сәламәтлек сиңа телибез.

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең, кызың, улларың.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

*Хөрмәтле хезмәттәшебез, район газетасының чуваш теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары **Елизавета Тимофеевна Илюшкинаның** бу көннәрдә икеләтә юбилее: яше һәм хезмәт стажы буенча. Шәхси календарендә аңа бүген 60 яшь, шуның 30 елын Елизавета Тимофеевна район газетасына багышлады.*

*Кадерле коллегабызны бу ике түгәрәк дата белән чын күңелдән котлап, без, редакция хезмәткәрләре, аңа озак елларга ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, күңел көрлеге телибез.*

*Олыгайдым, диеп уфтанма,*
*Һәрбер чорның - үзгә бизәге.*
*Балаларың, оныкларың үсеп,*
*Булсын сиңа тормыш терәге.*
***Район газетасы коллективы.***

## Белдерүләр

**САТАБЫЗ**

**Ретрансляция районында яңа капиталь гараж.** Адрес: Ленинградская ур., 11 - 3.

***

**1994 елгы, кара төстәге ВАЗ - 21061.** Тел.: 2 - 26 - 15.

***

**Йөреп торган ВАЗ - 2106. Кыйммәт түгел.** Адрес: Гыйматдинов ур., 120 - 4.

***

**ТАИР - 150ВХС В - 1 - 01. Бәясе 6 млн. сум.** Ад[...] Кошки авылы, Новая ур., 4. Тел.: 2 - 18 - 65.

***

**Стенка, кухня гарнитуры, телевизорга тумбочка, тегү машинасы (чит илдә эшләнгән).** Тел.: 2 - 29 - 47.

***

**ВАЗ - 21011.** Адрес: Молодежная ур., 12а - 1.

***

**1993 елгы ВАЗ - 2107.** Тел.: 2 - 25 - 74.

***

**Гагарин урамында 4 - 1 адресы буенча 2 бүлмәле хосусыйлаштырылган фатир, телефоны бар.** Гагарин ур., 4 - 4 адресына мөрәҗәгать итәргә.

***

**5 х 3,5 метрлы мунча бурасы.** Югары Норлатта Ш.Мөхәммәтьяровка мөрәҗәгать итәргә.

***

**3 бүлмәле фатир.** Московская ур., 5 - 45.

***

**Шәһәр үзәгендә 3 бүлмәле фатир.** Тел.: 5 - 26 - 22.

***

**1984 елгы ВАЗ - 2105, 1979 елгы ГАЗ - 24. Кыйммәт түгел.** Тел.: 5 - 38 - 33.

***

**1983 елгы ВАЗ - 21013, 2103кә яңа терсәкле[...]** Тел.: 5 - 16 - 53.

***

**1996 елның сентябрендә чыккан ВАЗ - 21099. Бәясе килешү буенча.** Тел.: 2 - 20 - 23 (эш вакытында).

**ТӨРЛЕСЕННӘН**

**1 бүлмәле фатир сатып алам.** Тел.: 2 - 10 - 14 (эш), 8дән 11 сәг.кә кадәр.

***

**Никифоров Анатолий исеменә документлар табучыны бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүләрен сорыйбыз.** Адрес: Синдряков ур., 25 - 24.

***

**Абдрахманов Марс Сәлим улы исеменә бирелгән машина йөртү таныклыгы, лицензия, УАЗ - 31512 машинасына техталон табучыны бүләк бәрабәренә Промышленная ур., 5 - 1 адресы буенча иясенә кайтаруны сорыйбыз.** Тел.: 5 - 27 - 57.

***

**Өйдә машинкада басам.** Тел.: 2 - 29 - 47.

***

**Михайлов Геннадий Николаевич исеменә документлар табучыны бүләк бәрабәренә промышленность базарында иясенә кайтаруын үтенәм.**

***

**Яшәп торырга бер бүлмәле фатир кирәк.** Тел.: 5 - 37 - 69.


**УТТ тукталышында «Берт» кибете филиалы ачылды. Сыра, сигаретлар, продуктлар түбән бәя буенча. Без иртәнге 7дән кичке 8гә кадәр эшлибез. Рәхим итегез!** Лицензия - Б - 97 № 048355.

**Идел Буе региональ наркология үзәге**

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә.**

**Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 24 октябрьдә, 7 ноябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.